**РРЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. /факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноябрь 2020 ел № 272

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, Азнакай муниципаль районы Уставының 7 статьясы нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләрне башкару срокларын билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары
Р. Р. Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
№ 2020 ел

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча эшләр башкару сроклары**

| № | Генераль план проектын әзерләү буенча эшләрне үткәрү тәртибе | Эшләрне башкару вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Азнакай муниципаль районы "Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү эшләрен оештыру | 2020 елның IV кварталы |
| 2. | Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектының беренче редакциясен әзерләү һәм килештерү | 2020 елның IV кварталы-2021 елның I кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1.<br><br><br>3.2.<br>3.3.<br><br><br>3.4.<br><br><br><br>3.5. | «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектының ахыргы редакциясен әзерләү, фикер алышу һәм килештерү.<br>«Кәкре Елга авыл җирлеге»муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын килештерү, бастырып чыгару.<br>Ачык тыңлаулар үткәрү.<br>"Кәкре Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын раслау.<br>Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы 5,6 өлешләре нигезендә "Кәкре Елга авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты нигезләмәләрен бастырып чыгару<br>Азнакай муниципаль районының «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына үзгәрешләр кертү проектын җибәрү. | I-II квартал 2021 ел. |